РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ БОЛЬШЕШИНАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422054, Республика Татарстан,
Сабинский район,с.Большой Шинар,
ул. Кооперативная,дом 36
тел. (84362) 41-2-11

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ШЫҢАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422054, Татарстан Республикасы,
Саба районы,Олы Шыңар авылы,
Кооператив урамы, 36 йорт
тел. (84362) 41-2-11

e-mail: bshin.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
21.06.2024

КАРАР
№ 11

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең җирләү өлкәсендәге җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешенә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советы Карар итте:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советына Саба муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл Башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

Җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт булдыру һәм аның эшчәнлеге тәртибен раслау;

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы тарафыннан әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы кабул иткән очракта Олы Шыңар авыл башкарма комитетына :

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

әлеге карарны тормышка ашыруны тәэмин итү максатларында 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү хакында Саба муниципаль районы Советы Карары проектын эшләү һәм бюджет законнары нигезендә карауга тапшыру.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/shinar адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Карар рәсми бастырып чыгарган кеннән үз көченә керә.

5. Карарның үтәлешен тикшерүне үз өстемә алам.

Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгы: А.Г.Гарипов